СОВЕТ МАЙДАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ МӘЙДАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

07.09.2018 | с. Майдан | № 41-189

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Советының 30.04.2013 елдан № 29-156 «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегендә халык алдында тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» карары нигезендә, авыл җирлегендә яшәүчеләрнең проект буенча фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатыннан чыгып,

Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» гы Карары проектын 1 нче кушымта нигезендә кабул итәргә һәм аны халык алдында тыңлауларга чыгарырга.

2. Расларга:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен №2 кушымта нигезендә;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибен №3 нче кушымта нигезендә.

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Советының 2018 елның 12 октябрендә 10.00 сәгатьтә Мәйдан КФҮ бинасында (Мәйдан авылы, Совет ур., 55) «Татарстан Республикасы Югары Ослан

муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрергә.

4. Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан кергән тәкъдимнәрне гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Советына карау өчен кертергә.

5. 2018 елның 10 сентябренә кадәр әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru), Мәйдан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы В. В. Михеев